| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА АНДРЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АНДРЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Андреевка ав. КАРАР

«26» октябрь 2020 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 6 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Ленин урамындагы "Яшьләр" балалар мәйданчыгында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә Гагарин урамы 1-8 санлы йортлардан, Зайкин урамы 2-17 санлы йортлардан, Ленин урамы 3-47/2 санлы йортлардан, Бакча урамы 1-27 санлы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә

2. 2020 елның 6 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка К.Маркс урамындагы "Үзәк" балалар мәйданчыгында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә К.Маркс урамы буенча 5-35 санлы йортлардан, Н.И. Маслаков урамы буенча 1-48 нче йортлардан, Басу урамы буенча 1-58 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 6 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Н.И. Маслаков урамы 67нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә Буранов урамы буенча 2а-20 санлы йортлардан, К.Маркс урамы буенча 37-75нче йортлардан, Н.И. Маслаков урамы буенча 50-90 нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Андреевка авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

6. Утвердить вопрос, выносимый на сход граждан:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлегенең Андреевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү

белән һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Андреевка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, уалган кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, җәю).

Урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

« РИЗА»　　　　　　　　　　«КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында  http://nurlat.tatarstan.ru/rus/andreevka.htm/, бастырып чыгарырга,  Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Андреевка авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Егорова Н.И.